булган урыннарда яңа биналар төзелми башлады. Җәмгыятебез зиратларыбызның тарихи һәм рухи әһәмиятен аңлауга килде.

Әмма ни кызганыч, бүгенге көндә әле меңләгән мөселман каберлекләре ташландык хәлдә. Моны төзәтү өчен шәһәр хакимияте дә, җәмәгатьчелек тә күп көч куярга тиеш, аерым чыгымнар да таләп ителәчәк. Шуңа күрә, зиратларда шәһәркүләм махсус өмәләр үткәрелүе сорала. Әйе, ул эш мөселманнар тарафыннан инде алып барыла башлады һәм бу тәҗрибәне киңәйтергә генә кала. Шулай ук саклап кала алмаган зиратларыбызның, кечкенә булса да, мемориаль такталары булдырылырга тиеш, мөгаен. Аларны күреп, шәһәр халкы белсен, мөэминнәребез дога кылып торсын өчен кирәк бу. Ә иң мөһиме – без һәм киләчәк буыннар «Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел» сүзләрен онытмасак иде.

*Айрат Фәйзрахманов,*
*тарих фәннәре кандидаты, Бөтендөнья татар*
*яшьләре форумы рәисе урынбасары*

## ЛӘБИБӘ ХӨСӘЕНИЯ

Ләбибә Һади (Кади) кызы Хөсәения (Һадиева) (1880–1921) – Казан шәһәрендә 1904–1918 елларда эшләгән татар кызлары өчен мәктәпне ачучы һәм мөдәррисе.

### Тәрҗемәи хәле

1880 елның 7 декабрендә Казан губернасы Чистай өязе (хәзерге Норлат районы) Яңа Әмзә авылында туган. Әтисе Һади Шәмсетдин

улы Бакиров, мәдрәсә тәмамлап, башта Яңа Әмзә авылында, соңыннан Казан артындагы (хәзерге Биектау районы) Чуаш Иле авылында мулла һәм мәдрәсәдә укытучы була. Л. Хөсәения башта әтисеннән, аннары бертуган абыйсы (булачак тарихчы) Мөнир Һадиевтан, Казанга күчкәч, Галимҗан Барудидан белем ала. Ләбибә үзе кебек яшь кызларга белем бирүне изге бурычы итеп санап үсә.

## Хезмәт юлы

1896 елга кадәр Сембер губернасы Барыш районы Терешка авылындагы миллионер Акчуриннарның йон юу фабрикасында эшче кызларны укыта. 1896 елда Мөхәммәдия мәдрәсәсе мөдәррисе Галимҗан Баруди (Галиев) чакыруы буенча Казанга килә. Г. Барудиның хатыны Маһруй Исхак кызы Галиевага (1904) өендә кыз балалар укытуда ярдәм итә башлый. Казанда беренче булып кызларны яңа ысул белән укыта башлаучы Маһруй абыстайдан җәдитчә укытырга өйрәнә. 1903 елда Маһруй ханым каты авыргач, кызлар мәктәбе эшен оештырып алып бару тулысынча диярлек Ләбибә кулына күчә.

## Ләбибә Хөсәения мәктәбе

«Ләбибә» мәктәбе – мөгаллимә Ләбибә башлангычы белән Казанда 1904 елдан 1918 елга кадәр эшләп килгән татар кызлары өчен урта уку йорты.

XVIII йөзнең II яртысыннан, татар бистәләрендә мәчетләр төзүне тыюлар бетерелгәч, Казан Россиядә Ислам динен укуукытуның иң зур үзәгенә әверелә. Күпчелек мәчетләр каршында мәдрәсәләр ачыла. XIX йөзнең соңгы чирегендә күп кенә ислам уку йортлары яңа ысуллар кулланып укытуга керешә. 1905–1907 еллар-

дагы инкыйлабтан соң Казанда дәүләтнеке булмаган 20 дән артык, шул исәптән татар кызлары өчен беренче дөньяви уку йортлары (Фатиха Аитова гимназиясе, Ләбибә Хөсәения мәктәбе) ачыла.

1903 елның җәендә Ләбибә Хөсәения Җамалетдин Хөсәенов дигән приказчикка тормышка чыгып, аның йортына, Нариман урамындагы Бигиевләр өенә күчеп китә. Көз көне шул фатирларының бер бүлмәсенә кыз балалар җыеп укыта башлый – үз мәктәбен ачып җибәрә. Шул рәвешчә, Казанда Ләбибә Хөсәенова мәктәбе мәйданга килә.

1904 елда, акча табыштырып, шул урамда үзләренә өй сатып алалар. Шуның ике бүлмәсен Ләбибә балалар укыту бүлмәләренә әйләндерә. Беренче елда укучы балалар саны 12 генә булса, икенче елда укучылар саны 20-25 җитә. Маһруй ханым Баруди (Галиева) вафатыннан соң, аның мәктәбендә укыган бай кызларының да кайберләре үзләренең элеккеге мөгаллимәләре булган Ләбибә Хөсәения мәктәбенә күчеп киләләр. Бер-ике ел эчендә мәктәп дүрт сыйныфлы булып китә. Укырга теләүчеләр күбәя. Мәктәп укырга-язарга өйрәтүне генә түгел, фәннәр башлангычлары белән таныштыруны – хисап, тарих, җәгъряфия укытуны да үз өстенә ала.

Мәктәпнең матди кыенлыкларын чишүгә укучы кызларның аналары – бай хатын-кызлары җәлеп ителә. Алар ирләрен мәктәпнең матди җитешсезлекләрен бетерүдә катнашырга мәҗбүр итәләр. Мәсәлән, 1905–1906 елларда сәүдәгәр Садыйк Галикәев мәктәпне яңа заманча парталар белән тәэмин итә.

Мәктәпне кысанлыктан коткарыр өчен, Казан сәүдәгәрләреннән бурычка акча алып, өйне ике катлы итеп күтәреп, уку мәйданын киңәйтәләр. 1910 елларга мәктәпнең даны бөтен татар дөньясына җәелә. Башка губерналардагы ерак авыллардан да бу мәктәпкә укырга киләләр. Мәсәлән, Саратов губернасы

Кузнецк өязе Черкиле авылыннан Әминә (1909 елда) һәм Хәдичә (1912 елда) Әхмероваларны укырга урнаштырулары билгеле.

1914 елда янгын чыгып, бина`яна. Бер игелекле (меценат) бай шул җәйдә мәктәп бинасын төзеп бирергә тәкъдим итсә дә, Л. Хөсәения мәктәбенең бер бай милкенә әйләнүенә ризалык бирми. Байлардан бурычка акча җыеп, үзе мәдрәсә салдырып, 1915 ел яз башына элеккеге мәдрәсә урынына салынган яңа бинада укуларны дәвам иттерә. Барлык бурычларын да (билгеле, иганәләр хисабына) байларга түләп бетерә.

## Мәктәпнең статусы

Татар кызлары өчен хәреф таныту, догалар уку, Коръәнне һәм кул эше өйрәнү белән чикләнгән ике сыйныфлы башлангыч мәктәп кенә ачарга рөхсәт ителә.

Шәһәрнең мәгариф идарәләрендә һәм канун каршында ул мәчет карамагындагы башлангыч, дин сабаклары укыта торган мәктәп саналган. Рәсми хакимиятләргә күрсәтелә торган кәгазьләрдә мәктәп «Казандагы җиденче мәчетнең дини-конфессиональ мәктәбе» («приходская школа») дип атала. Мәктәп мөдире – «вероучительница» исемен (дәрәҗәсен) генә йөртә.

1910 еллар башына мәктәп өч баскычлы ун сыйныфлы (дүртесе – башлангыч (ибтидаи), дүртесе – тулы булмаган урта (рөшди), икесе – урта (игъдади)) мәдрәсәгә әйләнгән була. «Женский мектеб при 4-ой мечети» дип язылган түгәрәк пичәт басылган шаһәдәтнамә бирелә торган була. Бу шаһәдәтнамә рус телендә язылып, кыз балалар вероучение (дин белеме), «татарская грамота» һәм арифметика предметларын гына үзләштергәннәр итеп күрсәтелә. Ә татар телендә һәр ел өчен нинди фәннәрдән имтиханнарда нинди бәһалар алганлы-

клары күрсәтелеп, аерым шаһәдәтнамәләр бирелә торган була. Болай «яшерену»ләрнең җитди нигезе бар. Мәктәп аерым бер кеше хисабына яши торган (хосусый) уку йорты санала һәм дәүләттән бер тиенлек ярдәм күрмәгән хәлдә, уку өчен түләү (гаиләләренең матди хәленә карап, 5 сумнан 25 сумга кадәр) һәм, башлыча, җәмәгатьчелек (иганә) хисабына яши. Канун буенча, татар хосусый мәктәпләрендә дин сабаклары укыту гына рөхсәт ителгән була, фәнни белем укыту катгый тыела.

## Укытучылар

Баштарак укытучылар мәсьәләсе гади генә хәл ителә: югарырак сыйныфта укучы кызларны түбән класстагы балаларны укытырга үзенә ярдәмче итеп билгели.

1914 елга «дарел мөгаллимат» – хатын-кыз укытучылар әзерләү мәктәбе рәвешенә кертер өчен, мәктәптә укыту эшенә югары белемле махсус әзерлекле укытучылар тартылалар. Түрәләр белән (рус телендә) сөйләшүләрне Татар укытучылар мәктәбенә 1907 елда экстерн имтихан тапшырып, укытучылык хокукын рәсмиләштергән, һәм Ләбибә Хөсәения мәктәбендә 1906 елда эшли башлаган Суфия Таһирова үз өстенә ала. Мәктәптә арифметика, җәгърафия, кул һөнәре дәресләрен укыта. Хатын-кызлар югары мәктәбенең (высшие женские курсы) тарих бүлеген тәмамлаган Фатыйма Дәүләткилдиева – тарих укытучысы, Мәскәү университетында, Парижның Сорбонна университетында физика-математика курсын үткән Сара Шакулова – геометрия, гимназия тәмамлаган Вера Антонова – рус теле, сәнгать укуханәсен тәмамлаган Александра Павлова – рәсем, гимназия тәмамлаган Мәдинә Сәгыйдова – табигать белемен укыта. Ләбибә мәктәбен тәмамлаган Галиева Әминә татар теле дәресләрен алып бара.

## Дарелмөгаллимат

Ләбибә Хөсәенова укытучылар мәктәбе турындагы хыялын тормышка ашыра: 1917 елның көзендә мәктәбен дарелмөгаллиматка әйләндерә.

– Инкыйлабтан соң Л. Хөсәения мәктәбе хатын-кызлар өчен укытучылар әзерләү мәктәбе итеп оештырыла.

– 1918-1919 елларда хатын-кыз укытучылар семинариясе.

– 1919-1920 елларда ир укытучылар мәктәбе белән берләштерелә.

Казан округының халык мәктәпләре директоры М. Н. Пинегинның хатыны Зөләйхә Алкина ире аркылы мәктәпкә инспекторлар барырга җыенганын ишетү белән, якын дусты Ләбибә Хөсәенованы кисәтә, мәктәптә аларны әзерлек чараларын күреп каршы алалар.

Ләбибә Хөсәенова 1921 елда тифтан вафат була.

*Әнвәр Нуриәхмәт улы Хуҗиәхмәтов,*
*педагогика фәннәре докторы, профессор,*
*Россиянең һәм Татарстанның атказанган укытучысы;*
*Рәмис Рәфәгать улы Нәсибуллов,*
*педагогика фәннәре кандидаты, доцент*